**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

№ 191-р 30 март 2015 ел

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре территорияләрен санитар чистарту буенча икеайлык чараларын оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.03.2015 ел, №430-р күрсәтмәсен үтәү максатында, фермалар территорияләренең һәм алар янәшәсендәге территорияләрнең экологик ветеринария-санитария торышын яхшырту мәсьәләсен хәл итү максатларында:

1. Авыл җирлекләре башлыкларына һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә 2015 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «икеайлык үткәрү турында»17.03.2015 ел, №161-р күрсәтмәсе белән игълан ителгән Авыл хуҗалыгы предприятиеләре, фермалар һәм аларның янәшәсендәге территорияләрне, биологик калдыкларны утильләштерү урыннарын санитар чистарту буенча икеайлык үткәрүне оештырырга тәкъдим итәргә.

2. Нурлат муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә, Нурлат район дәүләт ветеринария берләшмәсенә авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә һәм авыл башлыкларына икеайлык чараларын башкаруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

3. ТР Министрлар Кабинеты Баш идарәсенең Алексеевск территориаль бүлеге дәүләт ветеринария инспекторына тәкъдим итәргә:

- биологик калдыклар белән эш иткәндә ветеринария законнары таләпләрен үтәүне, биологик калдыкларны утильләштерү урыннарын һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре фермалары территорияләрен канәгатьләнерлек ветеринария-санитария хәлендә тотуны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

- атна саен пәнҗешәмбе көнне 09.00 сәгатькә кадәр. 2015 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә электрон адреска тәкъдим итәргә Emil.Shagidullin@tatar.ru фермалар территорияләрен һәм алар янәшәсендәге территорияләрне, биологик калдыкларны утильләштерү урыннарын

фотоматериаллар белән бергә санитар чистарту буенча чаралар үткәрү турында хисап.

Мәгълүматны №1 һәм №4 ТР МК боерыгы 18.03.2015 №430 формасына ярашлы рәвештә, арта барган нәтиҗә белән бирергә;

- юридик һәм вазыйфаи затларга карата ветеринария законнары таләпләрен бозу очракларында, Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы нигезендә, фотоматериаллар кушымтасы белән административ йогынты чаралары кулланырга.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгына (килештерү буенча)йөкләргә.

Нурлат муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин